**УДК 821.161.1**

# Х.Й. МИҢНЕГУЛОВ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ ТАТАР-ҮЗБӘК БАГЛАНЫШЛАРЫ

**Габидуллина Фарида Имамутдиновна**
*Елабужский институт Казанского (Приволжского) федерального университета, г. Елабуга, Татарстан, Российская Федерация*
e-mail: *farida-vip@mail.ru*

***Аннотация.*** *Статья посвящена исследованию татаро-узбекских литературных взаимосвязей в трудах известного ученого Х. Ю. Миннегулова. В ней определяются научно-теоретические принципы оценки взаимодействия литературных связей, на которые опирается ученый. Отмечается, что Х. Ю. Миннегулов подходит к исследованию в историческом контексте и опирается на конкретные примеры, связанные с деятельностью отдельных личностей.*

***Ключевые слова:*** *Х.Ю.Миннегулов, литературные связи, дружба народов, принцип оценки, контекст, эпоха.*

***Abstract.*** *The article is devoted to the study of Tatar-Uzbek literary interrelations in the works of the famous scientist H. Y. Minnegulov. It defines the scientific and theoretical principles of evaluating the interaction of literary connections, on which the scientist relies. It is noted that H. Y. Minnegulov approaches the study in a historical context and relies on specific examples related to the activities of individuals.*

***Key words:*** *H.Y.Minnegulov, literary connections, friendship of peoples, the principle of evaluation, context, epoch.*

Рәсәйдә яшәүче төрле халыклар әдәбиятлары арасындагы мөнәсәбәтләр тарихын төгәл һәм тирән яктырту филологлары алдында торган актуаль мәсьәләләрнең, берсе. Телләре, гореф-гадәтләре ягыннан бер-берсенә якын булган халыклар арасындагы әдәби багланышларны җентекләп өйрәнү исә аеруча да игътибарга лаек.

Үзбәк һәм татар халкының да тормышында, гореф-гадәтләрендә матди һәм рухи уртаклык зур. Ике кардәш халык арасында элек-электән икътисади, иҗтимагый мөнәсәбәтләр хөкем сөргән. Бу исә аларның әдәбиятлары арасындагы элемтәләрнең үсү һәм ныгуына да җирлек тудырган. Менә шуны искә алып, татар филологлары әледән-әле башка халыкларның әдәбиятлары тарихына мөрәҗәгать итәләр. Кардәш халыкларның галимнәре дә татар әдәбияты хәзинәләреннән үз әдәбиятларының үсү, ныгу сәбәпләрен эзлиләр.

Татар әдәбияты галимнәре дә татар мәдәнияте, татар тормышын үзбәк халкы мәдәнияте һәм тарихы белән бәйләнештә өйрәнү буенча нәтиҗәле эшчәнлек алып баралар. Бу уңайдан татар әдәбияты тарихы үсешенә зур өлеш

керткән галим - Хатыйп Йосыф улы Миңнегуловның фәнни эшчәнлеге дә аерым игътибарга лаек. Казан федераль университеты профессоры, әдәбият белгече, тюрколог, әдәби тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе күпкырлы эшчәнлегенең гармонияле синтезына ирешә алган галимнәрнең берсе. Бөтен көчен һәм сәләтен фәнгә – өйрәнелмәгән катламнарны ачуга, рухи мирас хәзинәләрен халыкка кайтаруга багышлаган әлеге искиткеч шәхеснең бу юнәлештәге хезмәтләре дә шактый.

"Татарларга аркадаш үзбәк галиме" мәкаләсендә ул болай дип яза: "Бер үк дәүләтләр, бигрәк тә Рәчәй, СССР мәмәләкәтләре составында яшәү дә бу кавемнәрнең үзара аралашу-керешүенә көчле йогынты ясый. Узган гасыр урталарында Үзбәкстанда ярты миллионнан артык татар яшәве үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли. (Без фәкыйрегез дә Урта Азия якларында елга якын гомер кичерде: заводта эшләде, мамык җыйды)" [2: 262]. Әлеге фикер теге яисә бу формада, үзенчәлекле тикшеренү лейтмотивы кебек, берничә мәкаләдә халыкара конференцияләрдә Хатыйп Йосып улының фәнни докладларында яңгырый, күпсанлы басмаларда чагылыш таба.

Хатыйп Йосып улы Миңнегуловның үзбәк-татар әдәби бәйләнешләрен җентекләп өйрәнүе табигый. Ул – хәзерге вакытта фән дөньясында әйдәп баручы галимнәребезнең берсе. Аны Татарстан Республикасында, якын һәм ерак чит илләрдә әдәбият белгече галиме, әдәби тәнкыйтьче, педагог, дәреслекләр авторы, җәмгыять эшлеклесе буларак яхшы беләләр. Х.Й. Миңнегулов хаклы рәвештә "Казан университетының атказанган профессоры", "Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе" (1994), "Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе" (2005) исемле мактау дәрәҗәләренә лаек, Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе лауреаты (1995), Россия Академиясенең гуманитар фәннәр академигы (1996), Кол Гали (1998), Гаяз Исхакый (2005), Җамал Вәлиди (2014), Сөббух Рәфыйков (2015) исемнәрендәге премияләр лауреаты, халыкара казах-төрек университетының атказанган профессоры.

Агымдагы елда үзенең күркәм 85 еллык юбилеен билгеләп үтүче галим 1939 елның 12 маенда Татарстан Республикасының Зәй районы Апач авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Хатыйп Миңнегуловның әтисе Бөек Ватан сугышында һәлак була. Башлангыч белемне туган авылында ала, аннары күрше Пидәр авылындагы җидееллык мәктәптә укый. Өлгергәнлек аттестатын алгач, бер еллап вакыт Таҗикстанның Ленинабад өлкәсендә эшли. Анасының авыруы аркасында туган авылына кайта: колхозчы, клуб мөдире булып хезмәт итә. 1959

нчы елда Казан шәһәренең Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә. 1967 нче елның ноябреннән һәм хәзерге вакытта да Казан федераль университетының татар әдәбияты кафедрасы укытучысы. 1972 нче елда "Сәйф Сараиның тәрҗемәләре һәм оригиналь әсәрләре" исемле кандидатлык, 1991 нче елда "Татар әдәбияты һәм Шәрык классикасы (Үзара бәгланышлар һәм поэтика мәсьәләләре)" темасына докторлык диссертацияләрен яклый. 1992 нче елдан Х.Й. Миңнегулов профессор исемен ала. Ул татар, рус, инглиз, казах һ.б. телләрдә чыккан 1820 дән артык басма авторы, шулар арасында – 76 китап (шуларның 26 монография , 4 дәреслек (5,9,10 нчы сыйныфлар өчен), 10 укыту һәм методик әсбап, күп программа, мәкалә һәм текстология эшләре авторы да.

Урта һәм XIX гасыр татар әдәбияты тарихы һәм шигърияте, шулай ук аның Шәрык классикасы белән бәгланышлары, Х. Миңнегуловның фәнни эшчәнлегенең төп өлкәсе булды. Ул күп кенә архив, кулъязма һәм басма материалларын җентекләп анализлау нигезендә күп кенә авторларның идея-сәнгать дөньяларын ачты (Йосыф Баласагуни, Ясәви һәм Бакыргани, Кол Гали, Котб, Мәхмүд Болгари, Хисам Кятиб, Мөхәммәдьяр, Шәмседдин Зәки, Акмулла, Муса Акъегетзадә, Заһир Бигиев, Ризаэддин Фәхреддин һ.б.). Аның ярдәме белән Тукай чорына кадәрге әдәби процессның күп үзенчәлекләре ачыкланды, татар сөйләм сәнгатендә күчүчәнлек мәсьәләләре, гореф-гадәтләр һәм новаторлык арасында бәйләнеш өйрәнелде. Х. Миңнегуловның басмалары фәнни-гамәли тормышта киң җавап алды. Бу материаллар һәм ясалган фәнни нәтиҗәләр галимнәр, укытучылар, студентлар тарафыннан актив кулланыла.

Югарыда әйтелгәнчә, Х.Ю. Миңнегуловның фәнни эшчәнлеге күпкырлы һәм ул татар халкының башка халыклар белән, шул исәптән үзбәк әдәбияты белән әдәби бәйләнешләрне өйрәнү белән дә нәтиҗәле шөгыльләнә. Мәсәлән, аның "Мәдәни җомга" гәҗитенең №27 санында басылып чыккан "Үзбәк дөньясында Тукай" мәкаләсен татар-үзбәк әдәбияты бәгланышларын ачыклау юлындагы эзләнүләренең бер нәтиҗәсе буларак карарга мөмкин. Галим әлеге мәкаләдә хәзерге үзбәк һәм татарларның әби-бабалары күп гасырлар буе үзара аралашып, берничә мәртәбә бер үк дәүләтләр (Алтын Урда, Россия, СССР) составында яшәгәнен. Нәваиның (1441–1502) һәр ике халык өчен дә үз һәм якын булганлыгын ассызыклый: "Бу кавемнәрнең этник яктан, тел, дин, мәдәният, сүз сәнгате җәһәтеннән үзара якынлыгы, охшашлыгы — дәлилләүне сорамый торган аксиома, хакыйкать. Тукай чорын да бу халыклар, гәрчә аерым хосусый үзенчәлекләргә ия булсалар да, тулаем алганда чагыштырмача гомуми

мөселман дөньясының вәкилләре рәвешендә каршылый. Үзара икътисади, мәдәни, рухи багланышлар тагын да көчәя. Идел-йорттан Урта Азия тарафларына күчеп килүче татарлар елдан-ел арта бара”, [3, 6].- дип яза ул. Галим фикеренчә, аерым тарихи сәбәпләр аркасында, XX йөз башында татарлар мәгърифәти, мәдәни яктан шактый алга китә, төрки дөньяда әйдәп баручы кавемнәрнең берсенә әверелә. Әгәр дә элегрәк татар яшьләренең күбесе Бохара, Сәмәрканд мәдрәсәләрендә укыса, соңрак Урта Азия кавемнәренең, шул исәптән үзбәкләрнең дә шактый гына үсмерләре Идел-йорттагы «Мөхәммәдия» (Казан), «Галия» (Уфа), «Хөсәения» (Оренбург), Эстәрлебаш, Троицк мәдрәсәләрендә белем ала. Ташкент, Кызылъяр, Семей (Семипалатинск), Кустанай һәм кайбер башка төрки шәһәрләрендә дә татар мәктәпләре ачыла. Күпләгән татар зыялылары (алар арасында шактый гына әдипләр дә бар: Г.Ибраһимов, М.Гафури, Ш.Бабич…) казах, үзбәк, кыргыз, каракалпак… кавемнәре арасында мөгаллимлек кыла. Татар китаплары, газета-журналлары, дәреслек-әсбаплары Төркестан тарафларында киң таралыш таба. Татарлар Урта Азия халыкларына мәгариф, матбугат, нәшрият, театр эшләрен оештыруда да зур ярдәм күрсәтә. Галим фикеренчә менә шундый иҗтимагый-тарихи контекстта татар сүз сәнгатенең, аның күренекле вәкиле Г.Тукайның да үзбәк рухи тормышында шактый мөһим роль уйнавын табигый һәм мантыйкый. Бу хакта үзбәк зыялыларының үзләре әйткән фикерләре белән  дә бүлешә: «Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр үк инде үзбәк халкы арасында татар әдәбияты бик күп таралган… Тукай — үз заманында ук үзбәк халкы арасында билгеле һәм танылган шагыйрь», — ди Үзбәкстанның халык шагыйре Гафур Голәм (1903-1966). Үзбәк классик әдибе Уйгун (Рәхмәтулла Атакузиев – 1905-1990) «Тукай давно знаком и близок узбекскому народу. Мы с давних пор, со школьных лет наизусть знали его прекрасные стихи, напечатанные в учебнике «Родная речь», – ди. – Мы от всей души считаем его своим учителем, своим поэтом».  Х. Миңнегулов Тукайны зурлаган, аның остазлыгын икърар иткән мондый фикерләр үзбәкнең күп кенә башка әдип-шагыйрьләре, галимнәре тарафыннан да әйтелгәнен искәртә: “Абдулла Арипов: «Тукай – үзбәк халкының да сөекле шагыйре. Аның теле дә, әсәрләренең рухы да безгә гаять үз һәм якын, аның сазы-моңнары безнең күңелләрдә дә аваздаш яңгыраш таба… Тукай кебек шагыйрьләргә ия халык бәхетле һәм үлемсез». Ләзиз Булатов: «Тукайның бөтен иҗаты, көрәше – чын фидакарьлек, чын каһарманлык  үрнәге, халыкка хезмәт итү, халык өчен көрәшү үрнәге!..  Аның рухын, исемен, иҗатын ничек кенә тәкъдир итсәк тә, аз булыр». Габделкадыйр Хәйсабиров: «Тукай

шул кыска гомерендә үзенең җырлы иҗаты белән татар халкының гына түгел, бөтен төрки галәмнең гаҗәеп бер шагыйренә, шагыйрьләребезнең, шигъриятебезнең пәйгамбәренә әверелә… Үзбәк әдәбиятын өч Габдулла күтәргән: Габдулла Кадыйри, Габдулла Каһһар, Габдулла Авлони. Мин әлеге исемлекне дәвам итеп, шуны әйтер идем: безнең әдәбиятны Габдулла Тукай да күтәргән. Тукайсыз үзбәк әдәбиятын күз алдына да китереп булмый» [3, 6].

Тукай иҗатының үзбәк әдәбиятындагы урыны, роле хакында шактый гына гыйльми-тәнкыйди тикшерүләр дә барлыгын да дәлилли галим: "Профессор Ләзиз Каюмов Тукай һәм Хәмзә Хәкимзадә иҗатларын чагыштырма планда яктырта, үзбәк шагыйренә татар авторының көчле йогынтысын ассызыклый. Тукай әсәрләренең үзбәкчәгә тәрҗемәләре хакында кызыклы мәгълүматлар бирә. Әдәбиятчы галим Шерали Турдыев Тукай һәм үзбәк әдәбиятын киң, тарихи яссылыкта тикшерә, бу мәсьәләгә мөнәсәбәтле мөһим фикер-күзәтүләрен бәян итә. Мәсәлән, ул татар шагыйренең Абдулла Кадыйри (1894-1939) иҗатына, аеруча аның сатирик әсәрләренә сизелерлек йогынты ясавын ассызыклый, ике шагыйрьдәге уртак, үзгә якларны күрсәтә. Ш. Турдыев язмасында янә бер мөһим факт телгә алына. Баксаң, «Иштиракиюн» («Коммунист») газетасының 1920 ел 15 апрель санында «Восточный поэт Абдулла Тукай» исемле бер мәкалә басылган икән. Анда Тукайны Шәрыкның бөек классиклары белән янәшә куйган мондый юллар бар: «Среди великих поэтов Востока, как Маари, Хафиз, Хайям, Саади, Навои, почетное место занимает также Габдулла Тукай. Он подготовил тюрко-татарских трудящихся к великой революции в России» [3:6].

Галим үзбәк әдәбиятында Тукайга багышланган әсәрләр булуын, мәсәлән, «Садои Туркестан» (Ташкент) газетасында 1914 елгы бер санында күренекле шагыйрь Тавалло (Тулаган Хуҗамеров – 1883-1937. Шәхес культы корбаны) «Мәрхүм Габдулла әфәнде Тукаевның шигырьләренә хөрмәт» исемле шигырен бастыруын искәртеп, андагы шигырь юлларын да мисалга китерә: «Мәрхүм Габдулла Тукай кеби яшь чагымда китмәсәм, яраткан шагыйрең булырга өметләнә ниятем… Гаҗәп түгел. Тавалло шигыре Габдулла шигыренә охшаса әгәр дидем, Ахирәттә табышырлар ике ятим".

Мәкаләдә шулай ук үзбәк-татар әдәби бәйләнешләрен махсус өйрәнеп, кандидатлык диссертациясе яклаган Ташкент галимәсе Лалә Мәгъсумованың да шулай ук бу ике халык сүз сәнгатен, Тукай иҗатын тарихи планда каравы да туктала: «Элекке чор әдәбиятына Нәваи һәм башка үзбәк әдипләре зур тәэсир ясаса, соңгы дәвер үзбәк әдәбиятына Габдулла Тукай һәм аннан гайре күп кенә

татар язучыларының тәэсире көчле булган. Гомумән, XIX йөзнең ахыры һәм XX гасырның башына татар әдәбияты төрки дөньяда… өлге хезмәтен үти. Л. Мәгъсумова үз хезмәтләрендә Тукайның үзбәк тормышындагы ролен яктыртуга, биредәге әдипләргә ничек, ни рәвешле тәэсир итүен ачыклауга зур урын бирә; Хәмзә, А.Кадыйри, Суфизадә, Мирмөхсин шигырьләрен Тукай әсәрләре белән чагыштырып, мөһим генә фикерләр әйтә, үзбәк авторларына татар шагыйренең һәм идея-тематик, һәм поэтик яктан көчле тәэсир ясавын искәртә. Бу галимә язмаларында үзбәк классик шагыйре Гафур Голәмнең Тукай турындагы фикерләре, татар сүз сәнгатенә, Казанга ихтирамы, җылы мөнәсәбәте хакында да факт-мәгълүматлар бар. Мәгълүм ки, Г.Голәм Һ.Такташ, Х.Туфан, С.Кудаш, М.Гафури, С.Хәким һәм татарның кайбер башка күренекле әдипләре белән шәхсән таныш та булган"[3, 6].

Галим үзбәк шагыйре Гафур Голәмнең янә бер фикерен ассызыклый: «Тукай үлгәннән соң, – дип яза ул үзенең «Габдулла Тукай безнең дә шагыйребез» исемле мәкаләсендә, – үзбәк халкы да татар халкы белән бергә тирән кайгы кичерде. Шагыйрь үлгәннән соң үзбәк укымышлылары матәм мәрасимендә катнашу өчен Казанга үзләренең вәкилләрен җибәрде. Тукайның үлүе мөнәсәбәте белән Ташкент, Хива, Сәмәрканд һәм башка шәһәрләрдә матәм кичәләре үткәрелде»[3: 6].

Чынлап та Тукай шигырьләре үзбәк дөньясында әүвәл оригиналда укыла. Бераздан аның тәрҗемәләре дә күренә башлый. Мәсәлән, шул ук Тавалло «Туган тел»не үзбәкчәгә күчереп, үзенең дәреслекләренә кертә. А.Кадыйри «Шүрәле» поэмасын һәм кайбер башка шигырьләрен тәрҗемә итә. Шунысы да мөһим: Тукай әсәрләрен үзбәкчәгә күчерүдә башка күренекле шагыйрьләр дә катнаша (Уйгун, Суфизадә, Ә.Мохтар, Г.Голәм, Х.Алимҗан, Мирмөхсин, Зөлфия һ. б.).

Тукайның күпчелек әсәрләре үзбәк телендә кат-кат басылган. Мәсәлән, 1946, 1960 һәм аннан соңгы елларда Тукайның «Сайланма әсәрләре» берничә мәртәбә дөнья күрә. Ә.Фәйзинең «Тукай» романы да А.Уразаев тарафыннан тәрҗемә ителгән. И.Нуруллинның «Габдулла Тукай» исемле гыйльми-әдәби әсәре дә А.Шәрәфетдинов тәрҗемәсендә үзбәк укучыларына җиткерелгән.

Хатыйп Йосыф улы Миңнегулов бүгенге көндә дә татар-үзбәк бәгланышларын өйрәнүне дәвам итә. Агымдагы ел башында гына "Күңелгә якын очрашулар" китабында ул " Татарларга аркадаш галим" [2: 262 - 267]. күләмле мәкаләсен бастырды. Мәкалә күренекле үзбәк галиме Бегали Касимовның (1943-2004) фәнни эшчәнлеген өйрәнүгә багышлана. Шактый зур

күләмле әлеге мәкаләдә галим Бегали Касимовның “милли уйганыш” исемле монографиясенә этрафлы анализ ясый. Хезмәтнең үзбәк халкының рухи тормышын, әдәбиятын өйрәнүдә генә түгел, ә үзара багланышларны яктыртуда мөһимлеген билгели.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин: галим үзе сайлаган һөнәрне яратып югары дәрәҗәдә, ә иң мөһиме – ләззәт белән башкара, тынгысыз хезмәте нәтиҗәсе буларак басылып чыккан калын-калын монографияләрен үзе үк республика буенча тарата, чит төбәкләргә почта аша да җибәрә. Профессор Хатыйп Миңнегулов - һәрвакыт чын күңелдән елмаючан, ихлас һәм яшьләргә һәрвакыт хәерхаклы галим. Без, аның шәкертләре, һәрвакыт аның күпкырлы эшчәнлегенә, чыгышлар ясаудагы осталыгына, көчле талантына, кабатланмас булуына, фәнни фикерләвенең тирәнлегенә һәм киңлегенә карап сокланабыз.

Алга таба да кардәш халыкларыбыз белән шулай ук тату һәм фәнни-мәдәни бәйләнештә яшәргә насыйп булсын. Бу юнәлештә хезмәт куючы галимнәребезгә, шул исәптән Хатыйп Йосып улы Миңнегуловка да, корычтай ныклы сәламәтлек, фәнни эзләнүләрендә уңышлар, нәтиҗәле ачышлар телибез. Татар-үзбәк бәйләнешләренең үсешендә һәм ныгуында профессор Хатыйп Миңнегуловның керткән хезмәте, һичшиксез, алга таба да тәфсилле өйрәнелер дигән теләктә калабыз. Халыклар арасындагы үзара фәнни-мәдәни һәм рухи мөнәсәбәтләрне ныгыту, баету өчен башкарган хезмәтләре өчен без остазыбызга бик тә рәхмәтлебез.

**Әдәбият:**

1. Закирзянов А.М. Стезя учёного: синтез традиций и новаторства (о научной и педагогической деятельности профессора Х.Ю. Миннегулова) // Филология и культура. – 2014. – № 1(35). – С. 339 – 343.
2. Миннегулов Х.Ю. Татарларга аркадаш үзбәк галиме / Созвучные душе встречи. – Казань: издво-во “Наследие нашего народа”, 2024. – С.262-267.
3. Миңнегулов Х.Ю. Тюрко-татарская словесность в контексте межлитературных связей. Монография. - Казан: Идел-Пресс 2016.- С.280-287.
4. Миннегулов Х.Ю. Үзбәк дөньясында Тукай // Мәдәни җомга, 2016. - №27. – Б. 6.